| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И<br>СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ<br>РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ<br>БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮҺӘМ<br>СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

__17.10.2019____ г.Казань № __851_______

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 19 ноябрендә 5868 номеры белән теркәлде

2019 елда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыруның сынау проектында катнашучы Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә күрсәтелә торган социаль хезмәтләр исемлеген раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 23 декабрендәге 1023 номерлы карары белән расланган 2014-2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасының 2014-2025 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне модернизацияләү һәм үстерү» кече программасының 5 нче кушымтасында китерелгән 2019-2021 елларга Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыру буенча сынау проектын гамәлгә ашыруның Чаралар планын («юл картасы»н), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыру турында» 2019 елның 23 маендагы 432 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2019 елның 30 июлендәге 634 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында боерык бирәм:

1. Расларга:

1 нче кушымтага (алга таба – 1 номерлы исемлек) ярашлы рәвештә өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар исәбендәге социаль хезмәтләрдән

файдаланучы затларга 2019 елда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыруның сынау проектында катнаша торган Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында, ятлар ярдәменә мохтаҗ булуын бәяләү нәтиҗәләре буенча өлкән яшьтәге гражданин (инвалид) кертелгән карау төркеменә бәйле рәвештә күрсәтелә торган социаль хезмәтләр исемлеген;

2 нче кушымтага (алга таба – 2 номерлы исемлек) ярашлы рәвештә, инвалидларны карауны гамәлгә ашыра торган гражданнар исәбендәге социаль хезмәтләрдән файдаланучы затларга 2019 елда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыруның сынау проектында катнаша торган Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында, ятлар ярдәменә мохтаҗ булуын бәяләү нәтиҗәләренә карап, инвалид кертелгән карау төркеменә бәйле рәвештә күрсәтелә торган социаль хезмәтләр исемлеген;

3 нче кушымтага (алга таба – 3 номерлы исемлек) ярашлы рәвештә, социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга 2019 елда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыруның сынау проектында катнаша торган Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында, ятлар ярдәменә мохтаҗ булуын бәяләү нәтиҗәләренә карап, өлкән яшьтәге гражданин (инвалид) кертелгән карау төркеменә бәйле рәвештә социаль озата бару буенча күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген.

2. Арча, Биектау, Яшел Үзән, Кукмара, Түбән Кама, Балык Бистәсе муниципаль районнарындагы, Яр Чаллы шәһәрендәге социаль яклау территориаль органнары җитәкчеләренә социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программаларын эшләгәндә (яңадан карaганда) 1, 2, 3 номерлы исемлекләрдән файдалануны тәэмин итәргә.

3. Арча, Биектау, Яшел Үзән, Кукмара, Түбән Кама, Балык Бистәсе муниципаль районнарында, Яр Чаллы шәһәрендә халыкка комплексы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләре директорларына халыкка социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга социаль хезмәт күрсәтүнең актуальләштерелгән хосусый программалары нигезендә социаль хезмәт күрсәтүне һәм социаль озата баруны тәэмин итәргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 17 октябрендәге 851 номерлы карарына 1 нче кушымта

Өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар исәбендәге социаль хезмәтләрдән файдаланучы затларга 2019 елда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыруның сынау проектында катнаша торган Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында, ятлар ярдәменә мохтаҗ булуын бәяләү нәтиҗәләре буенча өлкән яшьтәге гражданин (инвалид) кертелгән карау төркеменә бәйле рәвештә күрсәтелә торган социаль хезмәтләр исемлеге

| № | Социаль хезмәтнең аталышы | Социаль хезмәткә тасвирлама | Өлкән яшьтәге гражданинны (инвалидны) карау төркеменә бәйле рәвештә хезмәт күрсәтүгә максималь вакыт нормасы, минут | | | | | | | | | | Социаль хезмәт күләме (максималь саны) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 1 | | 2 | | 3 | | 4 | | 5 | | |
| | | | шәһәр | авыл | шәһәр | авыл | шәһәр | авыл | шәһәр | авыл | шәһәр | авыл | |
| **1. Социаль-көнкүреш** | | | | | | | | | | | | | |
| 1.1. | Социаль хезмәттән файдаланучы хисабына сатып алу һәм китереп бирү: | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | | | | | | | | | | | |
| | | социаль хезмәттән файдаланучыдан товар сатып алу һәм китереп бирү өчен заказ кабул итү; | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | товар сатып алу өчен социаль хезмәттән файдаланучыдан акча алу; | | | | | | | |
| | | заказ бирелгән товарны сатып алу; | | | | | | | |
| | | социаль хезмәттән файдаланучының өенә товарны китереп бирү, шулай ук саклау урынына урнаштыру зарурлыгы булганда, | | | | | | | |
| | | социаль хезмәттән файдаланучыга сатып алынган товар өчен касса чегын тапшыру, касса чегы буенча ахыргы исәп-хисапны ясау. | | | | | | | |
| 1.1.1. | азык-төлек, иң беренче чиратта кирәкле сәнәгый товарлар, санитария һәм | Хезмәт социаль хезмәттән файдаланучы зат яшәгән районда (500 метрга кадәр) | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | гигиена чаралары, тәрбия чаралары | урнашкан сәүдә объектларыннан авырлыгы 7 килога кадәрле товар сатып алуны һәм китереп бирүне күздә тота | | | | | | | |
| 1.1.2. | дару чаралары, медицина әйберләре | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | | | | | | | |
| | | медицина оешмасында рецепт алу, шул исәптән ташламалы (кирәк булуга карап); | 45 | 90 | 45 | 90 | 45 | 90 | 45 |
| | | дару чаралары һәм медицина әйберләре сатып алу | 30 | 70 | 30 | 70 | 30 | 70 | 30 |
| 1.1.3. | китаплар, газеталар, журналлар | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | | | | | | | |
| 1.1.3.1. | | кирәкле китаплар, газеталар, журналлар сатып алу, китапханәдән китеп алып килү һәм кире илтеп бирү, шулай ук | * | * | 15 | 15 | 15 | 15 | 15 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.1.3.2. | | басма матбугатка язылуны рәсмиләштерү | * | * | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 |
| 1.1.4. | мәдәният-ял чараларына билетлар | Хезмәт мәдәният-ял чараларына билетлар сатып алуны күздә тота | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 |
| 1.2. | Үзәктән җылытылмый һәм (яисә) су белән тәэмин ителмәгән торак урыннарда яшәүче социаль хезмәтләрдән файдаланучылар өчен: | | | | | | | | |
| 1.2.1. | су белән тәэмин итү**: | | | | | | | | |
| 1.2.1.1. | эчәр су белән тәэмин итү | Хезмәт күрсәтү якын-тирәдәге су чыганагыннан (500 м кадәр) 40 литр күләмендә су китерүне күздә тота<br>Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне үз эченә ала: | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | чиста савыт әзерләү (алып кайту өчен чиләк яки махсус җиһазланган арбада башка төрле савыт, аны саклау өчен савытлар); | | | | | | | |
| | | файдалану өчен яраклы иң якын су чыганагыннан су алу (бер мәртәбәдә иң күбе 7 литр); | | | | | | | |
| | | социаль хезмәтләрдән файдаланучының өенә су китерү; | | | | | | | |
| | | суны саклый торган савытларга бушату; | | | | | | | |
| | | кулланылган савытны социаль хезмәттән файдаланучы белән килешенгән урынга алып кую. | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.2.1.2. | гигиена процедураларын үткәрү өчен су белән тәэмин итү*** | Хезмәт күрсәтү иң якын су чыганагыннан (500 м кадәр) 50 литр күләмендә су китерүне күздә тота<br>Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне үз эченә ала: | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 |
| | | чиста савыт әзерләү (алып кайту өчен чиләк яки махсус җиһазланган арбада башка төрле савыт, аны саклау өчен савытлар); | | | | | | | |
| | | файдалану өчен яраклы иң якын су чыганагыннан су алу (бер мәртәбәдә иң күбе 7 литр); | | | | | | | |
| | | социаль хезмәтләрдән файдаланучының өенә су китерү; | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | суны саклый торган савытларга бушату; | | | | | | | |
| | | кулланылган савытны социаль хезмәттән файдаланучы белән килешенгән урынга алып кую. | | | | | | | |
| 1.2.2. | социаль хезмәттән файдаланучы хисабына ягулык сатып алу | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | 30 | * | 30 | * | 30 | * |
| | | социаль хезмәттән файдаланучыдан ягулык сатып алу һәм китереп бирү өчен гариза кабул итү; | | | | | | | |
| | | социаль хезмәттән файдаланучыдан ягулык сатып алу һәм китереп бирү өчен кулга акча алу; | | | | | | | |
| | | социаль хезмәттән файдаланучының ягулык сатып алу һәм китереп бирү өчен гариза белән мөрәҗәгать итүе; | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | социаль хезмәттән файдаланучыга ягулык китереп бирү вакытлары турында телдән мәгълүмат җиткерү; | | | | | | | |
| | | ягулыкны даими саклана торган урынына урнаштыру; | | | | | | | |
| | | социаль хезмәттән файдаланучыга сатып алынган ягулык өчен һәм ягулыкны китереп биргән өчен касса чегын бирү, касса чегы буенча ахыргы исәп-хисапны ясау. | | | | | | | |
| 1.2.3. | мичләргә ягу**: | | | | | | | | |
| 1.2.3.1. | торак урында мичкә ягу (ягып җылыту чорында) | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | 45 | * | 45 | * | 45 | * |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | мичне ягу өчен әзерләү (торакка (мунчага) каты ягулыкны кертү, салу, моржа капкачын ачу, яга торган һәм көл җыела торган урыннарны чистарту); | | | | | | | |
| | | янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәп, мичкә ягып җибәрү; | | | | | | | |
| | | ягу урынына каты ягулык салу; | | | | | | | |
| | | яга торган урынны тикшерү, көл савытын һәм морҗаны ябу; | | | | | | | |
| | | инвентарьны алып кую һәм мич тирәсен җыештыру; | | | | | | | |
| | | көл чыгару. | | | | | | | |
| 1.2.3.2. | мунча миченә ягу | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | мичне ягу өчен әзерләү (торакка (мунчага) каты ягулыкны кертү, салу, моржа капкачын ачу, яга торган һәм көл җыела торган урыннарны чистарту); | | | | | | | |
| | | янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәп, мичкә ягып җибәрү; | | | | | | | |
| | | ягу урынына каты ягулык салу; | | | | | | | |
| | | яга торган урынны тикшерү, көл савытын һәм морҗаны ябу; | | | | | | | |
| | | инвентарьны алып кую һәм мич тирәсен җыештыру; | | | | | | | |
| | | көл чыгару. | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.3. | Азык әзерләргә булышу һәм (яисә) әзерләү: | | | | | | | | |
| 1.3.1. | азык әзерләүдә ярдәм итү | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | 20 | 20 | 20 | 20 | 20 | 20 | * |
| | | азык-төлекне (куллану өчен әзер булганнарын һәм (яки) ярымфабрикатларны) юу; | | | | | | | |
| | | азык-төлекне (куллану өчен әзер булганнарын һәм (яки) ярымфабрикатларны) чистарту; | | | | | | | |
| | | азык-төлекне (куллану өчен әзер булганнарын һәм (яки) ярымфабрикатларны) турау; | | | | | | | |
| | | су кайнату; | | | | | | | |
| | | әзер ризыкны җылыту. | | | | | | | |
| 1.3.2. | ризык әзерләү | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | * | * | * | * | * | 90 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | азык әзерләгәндә социаль хезмәтләрдән файдаланучы затның теләкләрен ачыклау; | | | | | | | | |
| | | | социаль хезмәтләрдән файдаланучы белән менюны килештерү; | | | | | | | | |
| | | | социаль хезмәтләрдән файдаланучыдан алынган азык-төлекне һәм кухня приборларын әзерләү; | | | | | | | | |
| | | | азык-төлекне механик (юу, чистарту, кисү) һәм термик эшкәртүне үз эченә алган рецептура нигезендә беренче, икенче ашларны әзерләү; | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өстәлгә беренче, икенче ашларны берәр порция белән (кирәк булуга карап) бирү; | | | | | | | |
| | | азык әзерләгәннән соң кухняны җыештыру һәм савыт-сабаны юу. | | | | | | | |
| 1.4. | Ашаганда (ашатканда) ярдәм күрсәтү: | | | | | | | | |
| 1.4.1. | ризык бирү | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | * | * | * | * | * | 10 |
| | | 1) социаль хезмәттән файдаланучы затны ашау өчен әзерләү (социаль хезмәтләрдән файдаланучыны уңайлы итеп утырту, аның кулларын юдыру); | | | | | | | |
| | | 2) ашарга әзерләү өчен урын (өстәл, тумбочка, поднос) әзерләү; | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 3) ашау өчен савыт-саба һәм өстәл кирәк-яраклары (кирәкле савыт-сабаны һәм өстәл кирәк-яракларын сайлау) әзерләү; | | | | | | | |
| | | 4) әзер ризыкны җылыту; | | | | | | | |
| | | 5) ризык бирү | | | | | | | |
| 1.4.2. | ашату | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | * | * | * | * | * | 20 |
| | | социаль хезмәтләрдән файдаланучы затны ашату; | | | | | | | |
| | | ашаганнан соң социаль хезмәтләрдән файдаланучының кулларын, битен юдыру; | | | | | | | |
| | | ашаган урынны җыештыру, файдаланылган савыт-сабаны һәм өстәл кирәк-яракларын юу. | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.4.3. | су эчү режимы үтәлешен контрольдә тоту | Хезмәт күрсәтү су эчү режимы үтәлешен тәэмин итүне күздә тота | * | * | * | * | * | * | 5 |
| 1.5. | Торак урыннарны җыештыруда ярдәм күрсәтү (торак биналарны җыештыру): | | | | | | | | |
| 1.5.1. | торак урынны җыештыруда ярдәм күрсәтү | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота:<br>33 кв. метрга кадәр мәйданда идәннәрне коры килеш җыештыруда ярдәм итү;<br>идәннәрне юып чыгаруда ярдәм күрсәтү;<br>мебельдән, тәрәзә төпләреннән тузанны сөртеп алуда ярдәм итү. | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 | * |
| 1.5.2. | торак урынны җыештыру | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота:<br>33 кв. метрга | * | * | * | * | * | * | 35 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кадәр мәйданда идәннәрне коры килеш җыештыру (булган очракта тузан суырткыч ярдәмендә);<br>идәннәрне юу;<br>мебельләрне, тәрәзә төпләрен коры һәм (яки) юешләп җыештыру. | | | | | | | |
| 1.5.3. | чүп чыгару** | Хезмәт күрсәтү көнкүреш калдыкларын (1 чиләк) чыгаруны (төзелеш һәм зур габаритлы чүп-чардан тыш) күздә тотыла. | * | * | * | * | 10 | 10 | 10 |
| 1.5.4. | сыек көнкүреш калдыкларын чыгару** | Хезмәт күрсәтү канализация системасы булмаган торакларда яшәүче социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга сыек көнкүреш калдыкларын (1 чиләк) чыгаруны | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | күздә тота | | | | | | | |
| 1.5.5. | хосусый торак секторда яшәүче социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның йорт яны территориясен кардан чистарту, | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | * | * | * | 30 | 30 | 30 |
| | торак бинага керү мөмкинлеген тәэмин итү өчен (ноябрьдән март аена кадәрге чорда) | социаль хезмәттән файдаланучы булган кирәк-ярак коралларны (саплы көрәк, бәрчә, себерке) әзерләү; | | | | | | | |
| | | торак йортка һәм ишегалды корылмаларына керүне тәэмин итү өчен бер метрга кадәрле киңлектә, егерме метрга кадәрле озынлыктагы карлы юлларны чистарту. | | | | | | | |
| 1.6. | Социаль хезмәтләрдән файдаланучы зат акчасына | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | * | 60 | 60 | 60 | 60 | 60 |
| | | социаль хезмәттән | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | әйберләрне юарга, химчисткага, ремонтка тапшыру. аларны кире алып кайтып бирү** | файдаланучының юуны, химик чистартуны яки төзәтүне таләп итә торган әйберләрен җыю (авырлыгы 7 килограммга кадәр); | | | | | | | |
| | | социаль хезмәттән файдаланучыдан кер юган, химик чистарткан, төзәткәләгән өчен түләүгә акча алу; | | | | | | | |
| | | юу, химик чистарту, ремонт пунктларына әйберләрне илтеп бирү; | | | | | | | |
| | | социаль хезмәтләрдән файдаланучыга әйберләрне алып кайтып бирү; | | | | | | | |
| | | социаль хезмәтләрдән файдаланучыга квитанцияләрне тапшыру, ахыргы исәп-хисапны | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | ясау. | | | | | | | |
| 1.7. | Кер юу һәм үтүкләү: | | | | | | | | |
| 1.7.1. | машина белән юу | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | * | * | * | * | * | 20 |
| | | керләрне сортларга аеру (7 кг кадәр); | | | | | | | |
| | | махсус юу чараларын өстәп, керне кер юу машинасына салу; | | | | | | | |
| | | юңыру программасын сайлау; | | | | | | | |
| | | кер юу машинасыннан юылган керләрне алу; | | | | | | | |
| | | чиста керне элү; | | | | | | | |
| | | кипкән керне җыеп алу һәм саклана торган урыннарга урнаштыру. | | | | | | | |
| 1.7.2. | машина белән юдырганда ярдәм | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне | 15 | 15 | 15 | 15 | 15 | 15 | * |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | күрсәтү | күздә тота: | | | | | | | | |
| | | кер юу машинасыннан юылган керләрне алу; | | | | | | | | |
| | | чиста керне элү; | | | | | | | | |
| | | коры керне җыеп алу һәм аны саклый торган урыннарга урнаштыру. | | | | | | | | |
| 1.7.3. | кул белән юу яки кер юдыру машинасында ярымавтомат юдырту | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | * | 60 | 60 | 60 | 60 | 60 | |
| | | керләрне сортларга аеру (5 кг кадәр); | | | | | | | | |
| | | керне җебетү; | | | | | | | | |
| | | кул белән кер юу яки керне ярымавтомат кер юу машинасына салу; | | | | | | | | |
| | | керне машинада яки кул белән чайкату (чайкау өчен алу); | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | чиста керне элү; | | | | | | | |
| | | кипкән керне җыеп алу һәм саклана торган урыннарга урнаштыру. | | | | | | | |
| 1.7.4. | кер үтүкләү | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | * | * | * | * | * | 45 |
| | | социаль хезмтләрдән файдаланучы заттан кер үтүкләү өчен алынган кирәк-яракны әзерләү; | | | | | | | |
| | | социаль хезмтләрдән файдаланучы зат тарафыннан бирелгән чиста керләрне (7 кг кадәр) үтүкләү; | | | | | | | |
| | | үтүкләнгән керләрне саклана торган урыннарга кую. | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | социаль хезмтләрдән файдаланучы заттан кер үтүкләү өчен алынган кирәк-яракны җыештырып кую. | | | | | | | |
| 1.8. | Социаль хезмәтләрдән файдаланучы зат акчасына торак-коммуналь хезмәтләргә һәм элемтә хезмәтләренә түләү | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 |
| | | җылылык энергиясен, кайнар һәм салкын суны, газ куллануны исәпкә алу приборларыннан күрсәтмәләрне язып алу һәм вәкаләтле оешмаларга тапшыру; | | | | | | | |
| | | торак урыннар, коммуналь хезмәтләр, элемтә хезмәтләре өчен түләү (түләүләрне яңадан исәпләтү) өчен документлар рәсмиләштерү | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | (квитанцияләрне тутыру) | | | | | | | |
| | | торак урын, коммуналь хезмәт күрсәтүләр, элемтә хезмәтләре өчен түләүгә социаль хезмтләрдән файдаланучы заттан кулга акча алу; | | | | | | | |
| | | торак урын, коммуналь хезмәтләр, элемтә хезмәтләре өчен түләү; | | | | | | | |
| | | социаль хезмәтләрдән файдаланучыга квитанцияләрне тапшыру, ахыргы исәп-хисапны ясау. | | | | | | | |
| 1.9. | Сәламәтлек торышы буенча аларны мөстәкыйль рәвештә башкара алмаган затларга гигиена | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хезмәтләре күрсәтү: | | | | | | | | |
| 1.9.1 | кул тырнакларын кисү | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота:<br>социаль хезмтләрдән файдаланучы заттан кул тырнакларын кисү өчен алынган коралларны әзерләү;<br>социаль хезмтләрдән файдаланучы затка эш башкару тәртибе турында аңлату;<br>тырнакларны кисү, кулларны социаль хезмтләрдән файдаланучы зат кремы белән эшкәртү. | * | * | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 |
| 1.9.2 | аяк тырнакларын кисү | Хезмәт күрсәтү аскы очлыкларда кан тамырлары авырулары, | 20 | 20 | 20 | 20 | 20 | 20 | 20 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | шикәр чире, тырнакларның ачыктан-ачык күренеп тора торган йогышлы авырулары булмаганда гамәлгә ашырыла. Бер кулланыла торган бармакчы бияләйләр киеп башкарыла. | | | | | | | |
| | | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | | | | | | | |
| | | социаль хезмәтләрдән файдаланучы заттан аяк тырнакларын кисү өчен алынган коралларны әзерләү; | | | | | | | |
| | | кирәк булганда аякларны парландыру; | | | | | | | |
| | | социаль хезмәтләрдән файдаланучы затка эш башкару | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | тәртибе турында аңлату; | | | | | | | |
| | | тырнак кисү яки игәүләү (тырнакны кыскарту); | | | | | | | |
| | | социаль хезмәтләрдән файдаланучы зат кремы белән эшкәртү. | | | | | | | |
| 1.9.3. | чәчләрне тәрбияләү | Хезмәт күрсәтү көн саен чәчләрне тәрбия кылуны – тарауны күздә тота. | * | * | * | * | * | * | 5 |
| 1.9.4. | юындыру | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | * | * | * | * | * | 10 |
| | | юынганда ярдәм күрсәтү яки кулларны, битне, муенны, колакларны су белән юдырту йә гигиена чараларын кулланып юындыру; | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | сөлге (салфетка) белән сөртү. | | | | | | | |
| 1.9.5. | авыз эче куышлыгын карау | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | * | * | * | 10 | 10 | 15 |
| | | кирәкле коралларны һәм урынны әзерләү, социаль хезмәтләрдән файдаланучы затны процедура өчен әзерләү; | | | | | | | |
| | | тешләрне яки аңкауны карауда ярдәм итү (тешләрне (протезларны) чистарту); | | | | | | | |
| | | авыз эчен (телне, яңак тышчасын) чистарту; | | | | | | | |
| | | авыз эчен чайкату; | | | | | | | |
| | | хезмәт күрсәтү урынын җыештыру. | | | | | | | |
| 1.9.6. | кырындыру (кырынганда | Хезмәт күрсәтү ир-ат җенесендәге | * | * | * | * | 15 | 15 | 15 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ярдәм итү) | социаль хезмәтләрдән файдаланучы затларга куркынычсызлык техникасын үтәп гамәлгә ашырыла. | | | | | | | |
| | | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | | | | | | | |
| | | кирәкле коралларны һәм урынны әзерләү, социаль хезмәтләрдән файдаланучы затны процедура өчен әзерләү; | | | | | | | |
| | | сакалны, мыекны кыру (кырганда ярдәм итү); | | | | | | | |
| | | инструментларны һәм хезмәт күрсәтү урынын җыештыру. | | | | | | | |
| 1.9.7. | юындыру (юынганда ярдәм күрсәтү): | | | | | | | | |
| 1.9.7.1. | су коенганда ярдәм итү | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | * | 15 | 15 | 20 | 20 | * |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | душ яки ванна бүлмәсенә озату; | | | | | | | |
| | | юыну чараларын файдаланып, тәннең кул җитми торган урыннарында юганда булышу; | | | | | | | |
| | | сөлге белән тәннең кул җитмәгән урыннарын сөртүдә булышу; | | | | | | | |
| | | душ яки ваннан бүлмәсеннән чыкканда озата бару. | | | | | | | |
| 1.9.7.2 | душ яки ванна бүлмәсендә тулысынча коендыру | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | * | * | * | * | * | 55 |
| | | душ яки ванна бүлмәсенә озату; | | | | | | | |
| | | юыну чараларын кулланып, тулысынча бәдрәф кылу (ваннада яки душта тулысынча | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | юындыру); | | | | | | | |
| | | сөлге белән тулысынча сөртү; | | | | | | | |
| | | душ яки ваннан бүлмәсеннән чыкканда озата бару. | | | | | | | |
| 1.9.7.3 | урын өстендә тулысынча коендыру | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | * | * | * | * | * | 60 |
| | | социаль хезмәтләрдән файдаланучы затны урын өстендә юындыру өчен әзерләү; | | | | | | | |
| | | махсус чаралар яки су, шулай ук җайланмалар ярдәмендә тулысынча бәдрәф кылу (коендыру); | | | | | | | |
| | | сөлге белән тулысынча сөртү; | | | | | | | |
| | | лосьон яки крем белән эшкәртү. | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.9.7.4 | тәнне өлешчә бәдрәф кылу | Хезмәт күрсәтү сөртүне, тәһарәт алдыруны, гигиена ванналарын күздә тота | * | * | * | * | * | * | 20 |
| 1.9.7.5 | бәдрәфтән (савыттан) файдаланганда ярдәм итү | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | * | * | * | * | * | 15 |
| | | а) бәдрәфтән файдаланганда ярдәм күрсәткәндә: | | | | | | | |
| | | социаль хезмәтләрдән файдаланучы затны бәдрәфкә кадәр озата бару; | | | | | | | |
| | | киемне рәтләү (бәдрәфкә кергәч һәм чыккач); | | | | | | | |
| | | унитазга (яки санитар урындыкка) утырырга ярдәм итү; | | | | | | | |
| | | унитаздан (яки санитар урындыктан) торырга булышу; | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | социаль хезмәтләрдән файдаланучы затны сөртү яки юдырту, абсорбцияләүче эчке кием киюдә (кирәк булганда) ярдәм итү; | | | | | | | |
| | | аның кулларын юдырырга. | | | | | | | |
| | | б) савыттан файдаланганда ярдәм күрсәткәндә: | | | | | | | |
| | | социаль хезмәтләрдән файдаланучы затка тазын күтәртергә яки борылып, савыт куярга ярдәм итү; | | | | | | | |
| | | кулланганнан соң савытны чистартырга һәм йогышсызландырырга; | | | | | | | |
| | | социаль хезмәтләрдән файдаланучы затны юдыртырга; | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | абсорбцияли торган эчке киемне алыштырырга; | | | | | | | |
| | | аның кулларын юдырырга. | | | | | | | |
| 1.9.8. | эчке киемне алыштыру: | | | | | | | | |
| 1.9.8.1 | урын-җирне алыштыру | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | * | * | * | 20 | 20 | 20 |
| | | урын өстеннән урын-җирне салдырып алу; | | | | | | | |
| | | салдырылган урын-җирне социаль хезмәтләрдән файдаланучы зат белән килештерелгән урынга җыеп кую; | | | | | | | |
| | | чиста урын-җир комплектын җәю. | | | | | | | |
| 1.9.8.2 | тән киемен алмаштыру | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | * | * | * | 10 | 10 | 15 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | социаль хезмәтләрдән файдаланучы затның тән киемен салдыру; | | | | | | | |
| | | салдырылган киемне социаль хезмәтләрдән файдаланучы зат белән килештерелгән урынга җыеп кую; | | | | | | | |
| | | социаль хезмәтләрдән файдаланучы затка чиста комплект тән киеме кидертү. | | | | | | | |
| 1.9.9. | киенгәндә һәм чишенгәндә ярдәм күрсәтү. | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | * | * | * | 15 | 15 | 20 |
| | | киенгәндә ярдәм итү – максат һәм сезонга ярашлы нигездә әзерләнгән аяк һәм өс киемен кигертү; | | | | | | | |
| | | чишенгәндә ярдәм итү: өс, аяк киемен салу, | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | аларны саклана торган урыннарына кую. | | | | | | | |
| 1.10. | Хәрәкәт иткәндә (бер урыннан икенче урынга барганда) ярдәм итү: | | | | | | | | |
| 1.10.1 | караватта позицияләү | Хезмәт күрсәтү медицина оешмасы тәкъдимнәрен һәм социаль хезмәтләрдән файдаланучы затның хәл торышын исәпкә алып, урын өстендә озак ятудан тишелгән урыннарны, очлыкларның контрактурларын, үпкә чирен профилактикалау, сулыш алуны җиңеләйтү һәм көндез уңайлы тору, төнләү йокы өчен уңайлы яткыру | * | * | * | * | * | * | 15 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | максатларында гамәлгә ашырыла. | | | | | | | |
| | | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | | | | | | | |
| | | каты авырый торган караваттагы социаль хезмәтләрдән файдаланучы затларның тән торышын даими рәвештә үзгәртеп кору (табиб күрсәтмәләре, киңәшләре буенча) | | | | | | | |
| 1.10.2. | бер урыннан икенче урынга күчереп утырту (күчереп утырганда ярдәм итү), карават кырыена утырту | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | * | * | * | 5 | 5 | 5 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | караваттан кресло-коляскага (урындыкка) күчереп утырту (күчереп утырганда булышу), карават кырыена куркынычсыз ысул белән утырту; | | | | | | | |
| | | уңайлы һәм тотрыклы торышка китерү; | | | | | | | |
| | | караватка күчереп утырту (күчеп утырганда булышу), ышанычлы һәм авырту тудырмый торган ысул беләг караватка яткыру; | | | | | | | |
| | | караватта уңайлы торышка китерү. | | | | | | | |
| 1.10.3. | урамга чыкканда озата йөрү | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | * | * | * | 90 | 90 | 90 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | социаль хезмәттән файдаланучыга урамга чыкканда җыенырга ярдәм итү (киендерү, аяк киемнәрен кигертү, утырту һ.б.); | | | | | | | | |
| | | өеннән 1 км диаметрында социаль хезмәттән файдаланучыны озата йөрү; | | | | | | | | |
| | | социаль хезмәттән файдаланучы белән бергә аның өенә кайту, әгәр маршрутны килештергән вакытта башкача сөйләшенмәгән булса. | | | | | | | | |
| 1.11. | социаль хезмәттән файдаланучы затта бозылган функцияләрне коррекцияләү өчен билгеләнгән приборлардан файдаланганда | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ярдәм күрсәтү: | | | | | | | | |
| 1.11.1 | күзлек яисә колак аппаратлары белән файдалануда ярдәм итү | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота:<br>күзлек яки колак аппаратлары белән файдаланганда ярдәм итү (киертү, аппаратны урнаштыру, салдыру);<br>күзлекнең, аппаратның техник торышын һәм куркынычсыз булуын тикшерү | * | * | * | * | 5 | 5 | 5 |
| 1.12. | Социаль хезмәтләрдән файдаланучы хисабыннан | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота:<br>социаль хезмәттән | * | * | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | почта корреспонденциясе җибәрү** | файдаланучы зат әйтеп торып, А4 форматындагы 1 бит күләмендә хат (телеграмма) язу, посылка җыюда булышлык күрсәтү; | | | | | | | |
| | | социаль хезмәттән файдаланучыдан почта корреспон-денциясен (хат, телеграмма, посылка) җибәрү өчен кулга акча алу; | | | | | | | |
| | | социаль хезмәттән файдаланучы өеннән 500 м кадәрге диаметрда коррес-понденция (почта тартмасы яки почта бүлекчәсе аша) җибәрү; | | | | | | | |
| | | касса чегы буенча социаль хезмәттән файдаланучы зат белән ахыргы исәп-хисапны ясау; | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | почта корреспонденциясен уку. | | | | | | | |
| **2.** | **Социаль-медицина** | | | | | | | | |
| 2.1. | Сәламәтлеге буенча торышларында җитешсезлекләрне ачыклау максатында социаль хезмәттән файдаланучы затларны системалы рәвештә күзәтү | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | * | 15 | 15 | 15 | 15 | 15 |
| | | социаль хезмәттән файдаланучы затның тышкы кыяфәте һәм үз-үзен хис итүе буенча аның торышындагы үзгәрешләрне күзәтү, шул исәптән, ятып тишелгән урын-нар барлыкка килү хәтәрен вакытында ачыклау һәм алар-ны профилакти-калау максатында, социаль хезмәттән файдаланучы затның тән капламы һәм лайлалы тышчалардагы | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | үзгәрешләрен күзәтү | | | | | | | |
| | | социаль хезмәттән файдаланучы затның сәламәтлеге буенча торышын күзәтү журналына нәтиҗәләрне кертеп, контроль үлчәмнәр (тән температурасын, кан басымын үлчәгәндә) алганда булышлык күрсәтү; | | | | | | | |
| | | дару чараларын кабул итү вакытына, кабул итү ешлыгына, кабул итү ысулына һәм аларның яраклылык вакытларына бәйле табиб күрсәтмәләре үтәлешен тикшерүдә тоту. | | | | | | | |
| **3.** | **Социаль-психологик** | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.1. | Социаль-психологик патронат | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 |
| | | социаль хезмәттән файдаланучы затның психологик халәтен системалы рәвештә күзәтеп тору; | | | | | | | |
| | | килеп туган хәлдән чыгу максатларында әңгәмәләр үткәрү. | | | | | | | |
| **4.** | **Яшәешендә чикләмәләре булган социаль хезмәттән файдаланучы затны** **арттыру максатларында күрсәтелә торган хезмәтләр** | | | | | | | | |
| 4.1. | Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль-тернәкләндерү чаралары уздыру | Хезмәт социаль-тернәкләндерү технологияләреннән файдаланып, социаль хезмәттән файдаланучы зат белән дәрес үткәрү рәвешендә күрсәтелә. | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 |

* - хезмәт күрсәтелми

** - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1993 елның 6 февралендәге 105 номерлы кара йөкләнеш нормаларын исәпкә алып (башка эш белән чиратлаштырганда авырлыкларны тапкырга кадәр) – 10 кг, авырлыкны эш сменасы дәвамында даими күтәрү һәм күчерү – 7 к

*** - хезмәт хосусый мунчага ия булган социаль хезмәттән файдаланучы затка күрсәтелә

*Искәрмә:*
*Социаль хезмәттән файдаланучы, типиклаштыру уздырылганчыга кадәр үзләре белән формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турында килешү төзелгән затларга социаль программасындагы социаль хезмәтләр җыелмасы караунең 1 нче төркеме буенча билгелә*

Татар
халык
социал
2019 е
номер

Инвалидларны карауны гамәлгә ашыра торган гражданнар исәбендәге социаль хезмә
2019 елда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын о
катнаша торган Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тар
күрсәтү формасында, ятлар ярдәменә мохтаҗ булуын бәяләү нәтиҗәләренә карап, инвал
бәйле рәвештә күрсәтелә торган социаль хезмәтләр исемлег

| № п/п | Социаль хезмәтнең аталышы | Социаль хезмәт күрсәтүнең тасвирламасы һәм аның күләме | Өлкән яшьтәге гражданинны (инвалидны) карау төркеменә бәйле рәвештә хезмәт күрсәтүгә максималь вакыт нормасы, минут | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| **1.** | **Социаль-педагогик** | | | | | | |
| 1.1. | Өлкән яшьтәге | Социаль хезмәт күрсәтүнең | * | * | 30 | 30 | 30 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | гражданинның (инвалидның) торак урынын адаптацияләү мәсьәләсе буенча консультация бирү | составы: | | | | | | |
| | | 1) өлкән яшьтәге гражданинның (инвалидның), аның бозылган яшәеш эшчәнлеген, ярдәмче җайланмалардан файдалануның куркынычсызлыгын һәм зарурлыгын исәпкә алып, яши торган тирәлеген оештыру мәсьәләсе буенча консультация бирү; | | | | | | |
| | | 2) өлкән яшьтәге гражданинны (инвалидны) карауны гамәлгә ашыручы гражданинга тернәкләндерү һәм карау чаралары, өлкән яшьтәге гражданинның (инвалидның) тормыш сыйфатын яхшырту ысуллары турында мәгълүмат бирү. | | | | | | |

* - хезмәт күрсәтелми

Татар
халык
социа
2019 е
номер

Социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга 2019 елда өлкән яшьтәге гражданнарны һ
карау системасын оештыруның сынау проектында катнаша торган Татарстан Республик
күрсәтү оешмалары тарафыннан өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында, ятлар ярдә
нәтиҗәләренә карап, өлкән яшьтәге гражданин (инвалид) кертелгән карау төркеменә бәйл
буенча күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге

| № т/б | Социаль озата бару буенча хезмәт күрсәтүнең атамасы | Хезмәт күрсәтүне тасвирлау | Өлкән яшьтәге гражданинны (инвали бәйле рәвештә хезмәт күрсәтүгә нормасы, мину | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 1 | | 2 | | 3 | | |
| | | | шә-һәр | авыл | шә-һәр | авыл | шә-һәр | авыл | ш һ |
| **1.** | **Медицина ярдәме күрсәтүдә булышлык күрсәтү** | | | | | | | | |
| 1.1. | Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүдә булышлык күрсәтү һәм озатып бару | Хезмәт ашыгыч медицина ярдәме буенча кизү торучы табибны яки ашыгыч медицина ярдәме бригадасын чакыртуны күздә тота. | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 | |
| 1.2. | Медицина оешмасына госпитализацияләүдә | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | * | 60 | 60 | 60 | 60 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | булышлык күрсәтү | госпитализацияләү өчен кирәкле документларны җыю;<br>госпитализацияләү алдыннан әйберләр җыюда ярдәм итү;<br>махсуслаштырылган автотранспорт чакыру. | | | | | | | |
| 1.3. | Табиб-белгечләргә язылуда булышлык итү | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота:<br>медицина ярдәмен күрсәтү өчен табиб-белгечләргә язылу, шул исәптән диспансеризация узу, медик-социаль экспертиза үтү, шифаханә-курорт дәвалавына юлламалар алу максатларында да; | * | * | * | * | 20 | 21 | |
| 1.4. | Медицина оешмасына (медик-социаль экспертиза бюросына, Социаль иминият фонды бүлегенә) озата бару | Хезмәт социаль хезмәтләрдән файдаланучы затны медицина оешмасына, медицина-социаль экспертиза комиссиясе утырышына, Россия | * | * | 120 | 120 | 120 | 120 | 1 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Федерациясе Социаль иминият фонды бүлекчәсенә шифаханә-курорт дәвалануына юлламалар рәсмиләштерү өчен кирәкле гариза һәм документларны тапшыру, шифаханә-курортка юллама алу өчен озата баруны күздә тота. | | | | | | | |
| 1.5. | Медик-социаль экспертиза үткәрүдә ярдәм итү | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | | | | | | | |
| | | медицина-социаль экспертиза комиссиясе карарына шикаять әзерләүдә ярдәм итү (кабул ителгән карар белән килешмәгән очракта). | * | * | * | * | 15 | 15 | |
| **2.** | **Педагогик ярдәм күрсәтү** | | | | | | | | |
| 2.1. | Инвалидларның психофизик үсеш үзенчәлекләрен, | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | шәхси мөмкинлекләрен исәпкә алып, белем һәм (яки) һөнәр алуга булышлык күрсәтү | инвалидларны укыту белән шөгыльләнүче мәгариф оешмаларының белем бирү программалары турында мәгълүмат бирү; | * | * | 30 | 30 | 30 | 30 |
| | | социаль хезмәттән файдаланучы затны мәгариф оешмасына белем алу өчен яздыру; | * | * | 30 | 30 | 30 | 30 |
| | | социаль хезмәттән файдаланучы затны укыту өчен документлар туплау. | * | * | 30 | 30 | 30 | 30 |
| **3.** | **Юридик ярдәм күрсәтүдә булышлык күрсәтү** | | | | | | | |
| 3.1. | Социаль хезмәттән файдаланучы затларга документлар рәсмиләштерүдә һәм торгызуда ярдәм күрсәтү | Хезмәт социаль хезмәтләрдән файдаланучы хисабыннан күрсәтелә (документларны рәсмиләштергәндә түләү зарурлыгы булганда). | * | * | 50 | 50 | 50 | 50 |
| | | Хезмәт күрсәтү социаль хезмәттән файдаланучы затка шәхесне таныклый торган документларны, башка (шул | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | исәптән социаль ярдәм чараларын, пенсияләрне, пособиеләрне, реабилитацияләүнең техник чараларын, шифаханә-курортта дәва алуны, тернәкләндерүне һ.б. алу өчен кирәкле) шәхси документларны алуда, социаль хезмәт күрсәтүләрнең хосусый программасын яңадан рәсмиләштерүдә (социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗлык шартлары үзгәрүгә бәйле рәвештә яки аның гамәлдә булу вакыты чыкканнан соң) ярдәм күрсәтүне күздә тота: | | | | | | |
| | | социаль хезмәтләрдән файдаланучы затка үзенең хокукларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны язу һәм документ- | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | ларның формаларын тутыру; | | | | | | | |
| | | социаль хезмәтләрдән файдаланучы затның турыдан-туры хокукларына кагыла торган документларны (белешмәләрне) җыюда һәм дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, гавами-хокукый функцияләр бирелгән башка оешмаларга тапшыруда булышлык күрсәтү; | | | | | | | |
| | | дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, гавами-хокукый функцияләр бирелгән башка оешмаларга тапшырылган документларны карау барышын һәм нәтиҗәләрен тикшерүдә тоту. | | | | | | | |
| 3.2. | Законнарда билгеләнгән тәртиптә түләүсез | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | * | * | 40 | 40 | 40 | 40 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | юридик ярдәм алуда булышлык күрсәтү | «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 324-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә түләүсез юридик ярдәм алу буенча хокукларны аңлату (юридик бюроларның адресларын, телефоннарын, эш режимнарын әйтү); | | | | | | | |
| | | социаль хезмәтләрдән файдаланучы затның законлы хокукларын тормышка ашыру өчен гамәлдәге законнарга туры китереп, кирәкле документлар исемлеге турында мәгълүмат бирү, документларның билгеләнешен һәм эчтәлеген аңлату, аларны рәсмиләштерүдә ярдәм күрсәтү. | | | | | | | |
| **4.** | **Социаль ярдәм күрсәтүдә булышлык итү** | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.1. | Социаль ярдәм, социаль түләүләр һәм пенсия алуда булышлык күрсәтү: | | | | | | | | |
| 4.1.1. | гариза һәм документлар рәсмиләштерүдә ярдәм күрсәтү | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота:<br>социаль ярдәм, социаль түләүләр, пенсия билгеләү өчен кирәкле документларны тутыруда (рәсми-ләштерүдә) ярдәм күрсәтү;<br>вәкаләтле органга электрон рәвештә гариза һәм документлар тапшыруда ярдәм күрсәтү;<br>Вәкаләтле органда социаль ярдәм, социаль түләүләр, пенсия билгеләү өчен кирәкле документларны карау барышын контрольдә тоту. | * | * | 45 | 45 | 45 | 45 | |
| 4.1.2. | ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләтле | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне | * | * | 45 | 45 | 45 | 45 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | органда социаль хезмәтләрдән файдаланучының мәнфәгатьләрен яклау | күздә тота: | | | | | | |
| | | социаль хезмәтләрдән файдаланучы өчен социаль ярдәм чараларын, социаль түләүләр һәм пенсия рәсмиләштерү максатларында вәкаләтле органнарда социаль хезмәтләрдән файдаланучы зат мәнфәгатьләрендә эш итүгә ышаныч кәгазе рәсмиләштерүдә булышлык күрсәтү; | | | | | | |
| | | социаль ярдәм чараларын, социаль түләүләрне һәм пенсия рәсмиләштерү өчен кирәкле булган документларны вәкаләтле органга йә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган күпфункцияле үзәккә илтеп тапшыру; | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | социаль хезмәтләрдән файдаланучы затка социаль ярдәм чаралары, социаль түләүләр, пенсия алу хокукы турында рәсмиләштерелгән документларны тапшыру. | | | | | | | |

* - хезмәт күрсәтелми

*Искәрмә:*
*Социаль хезмәттән файдаланучы, типиклаштыру уздырылганчыга кадәр үзләре белән формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турында килешү төзелгән затларга социаль х программасындагы социаль озата бару буенча хезмәтләр җыелмасы карауның 1 нче төрк*